| | |
|---|---|
| ГЛАВА МОЛЬКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘЛКИ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**03.11.2022ел.** **Мәлки авылы** **№ 1**

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Мәлки авыл җирлегенең
Мәлки авылында гражданнар
җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗномерлы Федераль законының 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 18 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Мәлки авылы, Лесная урамы, 52 нче йорт адресы буенча урнашкан Мәлки төп гомуми белем бирү мәктәбе бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегендә ***үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының беренче этабын*** *билгеләргә.*

2. 2022 елның 22 ноябрендә 11 сәгать 30 минутта Мәлки авылы, Молодежная урамы, 2 нче йорт янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Мәлки авылында ***үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының икенче этабын*** билгеләргә.

3. 2022 елның 25 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Мәлки авылы, Гагарин урамы, 5 нче йорт янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Мәлки авылында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын*** билгеләргә.

4. 2022 елның 28 ноябрендә 13 сәгать 30 минутта Мәлки авылы, Почта урамы, 18 адресы буенча урнашкан күпфункцияле үзәк бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Мәлки авылында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын*** билгеләргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр

балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:*

- территорияләрне санкцияләнмәгән чүплекләрдән чистарту;
- урам яктырткычларын ремонтлау, материаллар сатып алу;
- Мәлки авылында материаллар сатып алып, Урюм елгасы аша платина төзү;

*б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, сүүткәргеч челтәрләрен ремонтлау;

*в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

*г) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;*

- материаллар сатып алып зиратларны чистарту һәм ремонтлау .»

«РИЗА »                                        «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны Мәлки авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Мәлки авыл җирлеге башлыгы                Ф.П.Поляков